ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2022 г. Заинск № 586

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 1.2 пунктында 13 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:
«- «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчә торган суга һәм эчә торган су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак урыннарына, җитештерү, иҗтимагый биналарны эксплуатацияләүгә, санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны оештыруга һәм үткәрүгә санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.1.3684-21».
2. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42